ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01» ноябрь 2019 г. № 430

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарының 3 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 29 декабрендәге 1287 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 20 июнендәге 497 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) карарына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү һәм хезмәт хакын тәртипкә салу максатыннан, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарының 3 нче кушымтасын яңа редакциядә бәян итәргә:

3 нче кушымта «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт

хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләгәндә кулланыла торган тапкырлык коэффициентлары».

2. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы карарының 3 нче кушымтасын исәпкә алып, штат расписаниесен тәртипкә китерергә.

3. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә хезмәт законнары таләпләре һәм әлеге карар нигезендә оештыру-штат чараларын үткәрергә.

4. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 апрелендәге 194 номерлы “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым бюджет өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында” карары белән билгеләнгән Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәт хакы күләме бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең вазыйфаи бурычлары күләме саклангнда һәм шул ук квалификация эшләрен башкарганда, 2019 елның 31 декабренә түләнгән хезмәт хакыннан ким була алмый.

5. Әлеге карар 2020 елның 1нче гыйнварыннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А. С. Авдеев**